| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БИЛЯР-ОЗЕРО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биляр-Озеро ав. **КАРАР**

«24» октябрь 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Биляр - Озеро торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Озерная урамы, 1-1, Молодежная урамы 1нче йорт, Садовая урамы1-54, Восточная урамы 1 – 16 йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Спорт урамы 1- 41, Дорожная ур., 1-17, Эшчеләр ур. 1-23, Овражный тыкрыгы 2нче йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2022 елның 11 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Южная ур., 1-23, Полевая ур. 1-26, Көнбатыш урамы 2 - 12, Зеленая урамы, 1 – 14 йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пункты территориясендә теркәлгән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Биляр-Озеро авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, кирпеч, туфрак, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

- урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- Биляр-Озеро авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча товарлар сатып алу, эшләр башкару.

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы В.С.Оренбургов